КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2026 ел, 26 май

г.Казань

№ б-1089

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районындагы Сокуры авыл җирлегенең Сокуры авылы чикләрендә Казан шәһәренең күпбалалы гаиләләренә бирелгән җир кишәрлекләрен газ белән тәэмин итү һәм аларга урам-юл челтәрен үткәрү максатларында:

1. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының Татарстан Республикасы Шәһәр яны урманчылыгы территориясендә Россия Федерациясе Урман кодексының 114 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында күрсәтелгән урманнар урнаша торган җирләрнең чикләрен проектлау документларын әзерләү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына әлеге боерыкның 1 пунктында күрсәтелгән җирләрнең чикләрен проектлау эшен билгеләнгән тәртиптә оештырырга, алга таба документларны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына раслауга кертергә.

3. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин